## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Банки Сукаеш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**09 ноябрь 2024 ел** **№ 1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Уставы нигезендә 2024 елның 09 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыен нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез 2025 елда Сукаеш авыл җирлеге Банки Сукаеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан , гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаиләләрдан тыш 400 сум күләмендә һәм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтэн өлкәннәрдэн 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Банки Сухояш авылының зиарат коймасын алмаштыру).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 95 гражданнар жыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 59.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 59,
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Банки-Сукаеш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

"Сез, 2025 елда Сукаеш авыл җирлеге Банки Сукаеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаиләләрдан тыш тыш 400 сум күләмендә һәм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтэн өлкәннәрдэн 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Банки Сухояш авылының зиарат коймасын алмаштыру).

.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сукаеш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында түбәндәге адреслар буенча: Зур Сукаеш авылы, Совет ур. 30 йорт, Банки-Сукаеш авылы, Үзәк ур. 56А йорт, һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сукаеш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сукаеш авыл җирлеге башлыгы Закирова З.Җ.